**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Олыяз авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 10 ноябре** **№ 5**

**Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Олыяз авылы, Яңа урам, 11 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

1. 2022 елның 26 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Олыяз авылы, Яңа урам, 11 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокллы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Олыяз авылының Яңа урамында чокырларны ямау, вак таш җәю һәм юлларны асфальтлау, смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Олыяз авылына энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу;
- Олыяз авылында урам юл челтәрен карап тоту (килешү буенча);
- Олыяз авылы яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту (кыргый үскән куакларны, агачларны кисү, төпләү, чүп-чар чыгару, ягулык-майлау материаллары сатып алу, бульдозер, экскаватор эше, ком белән тигезләү, вак аш салу, тимер-бетон плитәләр салу), смета документларын төзү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Олыяз авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов

ОГРН 1021607754051
ИНН 1623001879